| ГЛАВА<br>КЗЫЛ-ЯРСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КЫЗЫЛЪЯР<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

“17” ноябрь 2022 ел Кызылъяр авылы № 2

**Баулы муниципаль районы Кызылъяр авылы, Иске Чүти авылы, Уба авылы торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Баулы муниципаль районының «Кызылъяр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Баулы муниципаль районының Кызылъяр авыл җирлеге башлыгы район

Карар бирәм:

1. 1. 2022 елның 28 ноябрендә 8 сәгать 00 минутка Баулы муниципаль районының Кызылъяр авыл җирлеге торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә. Халык җыенын үткәрү урыны - Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Кызылъяр авылы, Киров урамы, 44Б адресы буенча урнашкан Кызылъяр балалар бакчасы.

2. 2022 елның 28 ноябрендә 9 сәгать 00 минутка Баулы муниципаль районының Кызылъяр авыл җирлегендә үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә. Җыен үткәрү урыны - Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Ф.Г. Яруллин исемендәге Кызылъяр урта мәктәбе, Татарстан Республикасы, Баулы

муниципаль районы, Кызылъяр авылы, Киров тыкрыгы, 19Б адресы буенча урнашкан.

3. 2022 елның 28 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Баулы муниципаль районының Кызылъяр авыл җирлегендә үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын билгеләргә. Халык җыенын үткәрү урыны – Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Кызылъяр авылы, Промзона адресы буенча урнашкан «Кызылъяр»

4. Халык исемлеген бүлүне территориаль билге буенча тормышка ашырырга:

1 этап: Совет урамының 1-128 номерлы йортыннан; Гагарин урамының 1-40нчы йортыннан; Ленин урамының 1-71нче йортыннан; Фрунзе урамының 1нче йортыннан 19А номерлы йортына кадәр.

2 этап: Киров урамында яшәүчеләр, 1нче йорттан 99нчы номерлы йортка кадәр; Тукай урамының 1нче йортыннан 54в номерлы йортка кадәр; Ленин тыкрыгында 1нче йорттан 12нче номерлы йортка кадәр,

3 этап: Тынычлык урамының 1-19нчы йортларыннан; Ф.Яруллин урамының 1нче йортыннан 20/2 номерлы йортка кадәр; М. Җәлил урамының 1нче йортыннан 19нчы йортка кадәр, Яшьләр урамының 1нче йортыннан 9нчы номерлы йортка кадәр яшәүчеләр.

5. 2022 елның 29 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Баулы муниципаль районының Иске Кызылъяр авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнарның җыелышын билгеләргә. Җыенны үткәрү урыны-Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Иске Чүте авылы, Елга урамы адресы буенча урнашкан фельдшер-акушерлык пункты.

6. 2022 елның 29 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Баулы муниципаль районының Кызылъяр авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнарның җыелышын билгеләргә. Халык җыенын үткәрү урыны-Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Уба авылы, Үзәк урамы, 25б адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне раслау:

Баулы муниципаль районының Кызылъяр авылында 300 (өч йөз) сум, Иске Чүти авылында 1000 (бер мең) сум, Уба авылында 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә сез килешәсезме? Баулы муниципаль районының Кызылъяр авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча:

Кызылъяр авылы:

1. Юлларны кардан чистарту;
2. Урамнарны яктырту фонарьларын сатып алу һәм урнаштыру;
3. Суүткәргеч челтәрләргә техник хезмәт күрсәтү;
5. Зиратларны төзекләндерү;
6. Ф.Яруллина урамында ямалы ремонт.

Иске Чүти авылы:

1. Урамнарны яктырту фонарьларын сатып алу һәм урнаштыру;
2. Юлларны кардан чистарту;
3. ЩПС юлларын сибү.

Уба авылы:

1. Юлларны кардан чистарту;
2. Балалар комплексын сатып алу һәм урнаштыру;
3. Ямочный ремонт, ЩПС сибү, автогрейдер белән тигезләү;
4. Урамнарны яктырту фонарьларын сатып алу һәм урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

8. Әлеге карарны Баулы муниципаль районының Кызылъяр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (https://www.bavly.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык, Совет Рәисе
Кызылъяр авыл җирлеге Э.А. Сафина